ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**14.11.2024**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 4300**

2025 елда Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын кайнар ризык белән белән тәэмин итүне оештыру

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның балансллы кайнар ризык белән туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү, балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 12 сентябрендәге «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирелә торган уку-укыту программалары буенча белем алучыларга түләүсез кайнар ризык бирүне оештыруга һәм аның белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирелә торган уку-укыту программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән тукланауының уртача бәясен раслау турында» 777 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 16 сентябрендәге «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү бәясе нормативын раслау турында» 789 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 10 сентябрендәге «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына акчалата түләүләр турында» 755 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елның 09 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче укучылары өчен һәр уку көненә 69 сум 43 тиен күләмендә түләүсез кайнар ризык тәэмин итүне оештырырга.
2. 2025 елның 09 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче укучыларына кайнар ризык тәэмин итү өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен һәр уку көненә 9 сум 60 тиен итеп билгеләргә.

3. 2025 елның 09 гыйнварыннан Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче түбәндәге категориядәге һәр укучыга кайнар ризык тәэмин итү өчен Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен һәр уку көненә 73 сум 15 тиен итеп билгеләргә:

- үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләдәге укучыга;
- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Норлат урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучы, ятим балалар һәм ата - ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен «Норлат балалар йорты» дәүләт белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләргә;

4. 2025 елның 09 гыйнварыннан җайлаштырылган уку-укыту программалары буенча белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәр укучыга һәр уку көненә Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 109 сум 66 тиен итеп билгеләргә.

5. 2025 елның 09 гыйнварыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар, РФ Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, РФ Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга» һәм «Тимер» батальонында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы, РФ Федераль иминлек хезмәтенең ТР буенча идарәсе хезмәткәрләре гаиләләреннән булган, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) яки инвалид булган гаиләләре (гаилә әгъзалары) балаларына Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен һәр уку көненә 109 сум 66 тиен күләмендә билгеләргә.

6. 2025 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә, «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку чорында кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

7. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы - җитәкче урынбасары Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин